**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Сапеевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Школьная, д. 53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района,
423326, Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ**
**Азнакай муниципаль районы Сәпәй авылы җирлеге башкарма комитеты**

Мәктәп урамы, 53В, Сәпәй авылы
Азнакай муниципаль районы
423326, Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

"27" февраль 2023 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 24.01.2014 № 78 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (05.05.2016 №30-1, 24.11.2016 №40, 04.09.2017 №60, 02.07.2018 №98, 14.03.2019 №124, 19.02.2020 №155, 11.08.2021 №33, 18.04.2022 №10, 18.10.2022 №20)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү өчен һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 24.01.2014 № 78 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәйавыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны (05.05.2016 №30-1, 24.11.2016 №40, 04.09.2017 №60, 02.07.2018 №98, 14.03.2019 №124, 19.02.2020 №155,

11.08.2021 №33, 18.04.2022 №10, 18.10.2022 №20) әзерләүгә керешергә:

1.1. 2023 елның 1 мартыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кергән үзгәрешләр белән 4, 16.5, 27, 29, 30 статьяларын туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru./.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Сәпәй
авыл җирлеге башкарма комитетының
карарына
1 нче кушымта
27.02.2023 ел №2

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыц «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм тозелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшлә уздыр срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен оештыру. | 2023 елн I квартал |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җир белән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 4, 16.5, 27, 29, 30 статьяларына үзгәрешләр кертү Федераль законның 29.12.2022 №612-ФЗ нигезендә, җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә комментарийлар әзерләү. | 2023 елн<br>I квартал |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар үткәрү. | 2023 е<br>I - II<br>кварта. |
| 3.1. | Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешенең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында һәм мәҗбүри кушымталар (гавами тыңлаулар беркетмәсе) һәм җир куллану кагыйдәләре проектының юнәлеше турында карар кабул итү өчен гавами тыңлауларның нәтиҗәләре хакында йомгаклау авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу турында һәм аны, кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә юнәлдерү урында Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башлыгына юллама. | |